ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

### 1 статья

“Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы $3^1$ өлешенә (2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), “федераль башкарма хакимиятнең миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен, тикшереп тору, күзәтчелек итү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы органының территориаль органына” сүзләрен “эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органына” сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

### 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан , Кремль
2019 ел, 01 март
№ 10-ТРЗ